Югары Чура авыл җирлеге Советы

# КАРАР

22 март, 2024 ел №14

**Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Пчеловод авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Чура авыл җирлеге Уставы нигезендә Югары Чура авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 07 апреленә 17 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы (2024 елның 5 февралендәге 1 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Пчеловод авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Пчеловод авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы карарына (2024 елның 5 февралендәге 1 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы:

«Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Пчеловод авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 4450 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Пчеловод авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- Пчеловод авылы юлларына вак таш салу һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылына насослар сатып алу һәм артезиан скважиналарын, су суыртү манараларын, су саклау зоналарын карап тоту, су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау һәм реконструкцияләү;

- Пчеловод авылының чишмә янында ял итү зоналары территорияләрен, балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылындагы зиратны карап тоту;

- Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машинист-тракторчы хезмәтләре;

- Пчеловод авылында су суыртү манаралары янына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру;

- Пчеловод авылына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру, видеокүзәтү системаларын урнаштыру; видеокамералар һәм видеокүзәтү системаларын ремонтлау һәм карап тоту;

- Пчеловод авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау, проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылында балалар һәм спорт мәйданчыкларын һәм аның тирәсендәге территорияләрне яктырту җайланмасын эшләү; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Пчеловод авылындагы чишмәне төзекләндерү һәм карап тоту?

2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы карарында (2024 елның 5 февралендәге 1 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү:

*тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау* (Пчеловод авылына урам яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, карап тоту, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау;

- *торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту* (Пчеловод авылы юлларына вак таш салу һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)

(Пчеловод авылында юлларны асфальтлау һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

(Пчеловод авылының урам юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машинист-тракторчы хезмәтләре)

*- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау* (насослар сатып алу, урнаштыру һәм артезиан скважиналарын, су суырту манараларын, су саклау зоналарын карап тоту)

(Пчеловод авылының су белән тәэмин итү челтәрләрен реконструкцияләү һәм йорт хуҗалыкларын гамәлдәге линиягә тоташтыру; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

*- торак пункт территориясен төзекләндерү* (Пчеловод авылының чишмә янында ял итү зоналары территорияләрен, балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын төзекләндерү һәм карап тоту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы В.Н. Андреев